ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
"АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ "
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«АКСУБАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН»

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СУНЧЕЛЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423050, Республика Татарстан, Аксубаевский муниципальный район, село Сунчелеево, ул. Ленина, 76.
Тел. (8-84344-4-98-24) ОГРН 1061665002080,
ОКПО 94318582, ИНН/КПП 1603004776/160301001

---

КАРАР

№ 9 «25» октября 2021 ел.

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге башкарма комитетының «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 02.08.2021 ел, №7 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге башкарма комитетының «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 02.08.2021 ел, №7 карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5. пунктының 2-10 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт адреслы реестрын алып бару һәм федераль мәгълүмати адреслы системаны эксплуатацияләүгә бәйле Регламентта кулланыла торган төшенчәләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Федераль мәгълүмати адреслы система турында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 28.12.2013 ел, № 443-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 19.11.2014 ел, № 1221 карары белән тәгәл яраштырып кулланыла.»;

1.2. 1.5. пунктының 11-17 абзацларын 3-9 абзацлар дип димәк санарга;

1.3. 2.6.1. пунктының 8 пунктчасында «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты» сүзләрен «Төзелгән килешү нигезендә муниципаль район Башкарма комитеты яисә җирле үзидарә органы»сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 2.6.4. пунктында «Башкарма комитетның структур бүлекчәсе» сүзләрен «Муниципаль районның җирле үзидарә органнары, Башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) халыкка игълан итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә (http://aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Сөнчәле авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: И.В.Крайнова